ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«29» декабрь 2020 ел № 1069

**Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында Нигезләмәне раслау хакында**

"Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1258 номерлы "Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 22 октябрендзге 946 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында Нигезләмәне расларга.

2. Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә ел саен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен

бүләкләү турында Килешү төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2021 ел бюджетыннан башлап (2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына), Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Мөхәрәмов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Башкарма комитеты
карары белән расланган

**Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләү турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге Нигезләмә югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләр бирүне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели (алга таба -башка бюджетара трансфертлар, Арча муниципаль районы).

2. Башка бюджетара трансфертлар югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләү өлешендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслашу максатыннан бирелә.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларының төп бүлүчесе - Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба - Министрлык).

4. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкка тиешле финанс елына әлеге Нигезләмәнең 2 пункында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Муниципаль физкультура спорт оешмасында башка бюджетара трансфертлар алу өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районын сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

спорт әзерлеге узучы затлар тарафыннан рәсми халыкара, бөтенроссия, регионара, республика ярышларында (Олимпия уеннарында, дөнья чемпионатларында, дөнья кубокларында, Европа чемпионатларында, ирләр һәм

хатын-кызлар арасында рәсми халыкара ярышларда, Европа Кубокларында, Россия чемпионатларында, Россия кубокларында, федераль округ чемпионатларында, Татарстан чемпионатларында, яшьләр һәм юниорлар арасында Россия беренчелекләрендә, Бөтенроссия универсиадаларында, дөнья, Европа яшүсмерләр уеннарында, Европа яшүсмерләр фестивальләрендә, өлкән яшүсмерләр арасында рәсми халыкара ярышларда, Россия яшьләр Спартакикиадасында, Россия укучылар Спартакиадасында, Россия чемпионаты финалларында, Россия Федерациясе Идел буе федераль округы беренчелекләрендә) узган календарь елда алынган югары нәтиҗәләр;

спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура- спорт оешмалары спортчы-инструкторлары һәм спортчылары тарафыннан үткән календарь ел өчен рәсми халыкара һәм бөтенроссия ярышларында (Олимпия уеннары, дөнья чемпионатлары, Европа чемпионатлары, Европа кубоклары, дөнья беренчелекләре, Бөтендөнья универсиадалары, Россия чемпионатлары, Европа беренчелекләре, Россия кубоклары, Россия беренчелекләре, Бөтенроссия универсиадалары) алынган югары нәтиҗәләр.

6. Башка бюджетара трансфертлар түбәндәге шартларда бирелә:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының норматив хокукый акты белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт оешмаларында югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга спорт резервларын әзерләүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә булу;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында (Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет бүленешендә) аларны финанслашу максатларында үтәү өчен кирәкле башка бюджетара трансфертлар тулы күләмдә бирелә торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу;

Әлеге Нигезләмәнең 11 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән килешү төзү.

7. Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

8. Тиешле финанс елына Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегенә башка бюджетара трансфертлар күләме (Si) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Si = Znj = 1 ((Ov x Чtpj) + (Bvrr x Чcpj)) x (100 + Cj) x 12 ,

биредә:

Ov - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән билгеләнгән

физик культура һәм спорт өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерлар оклады. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә, әлеге окладлар спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары тренерларының окладларына тигез кабул ителә;

Чtрj - Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан соңгы ике тәмамланган финанс елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә югары квалификацияле спортчылар әзерләүче тренерларның уртача еллык саны;

Bvrr - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән билгеләнгән спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмасында рәсми бөтенроссия һәм халыкара ярышларда катнашкан спортчылар һәм спортчыларга югары эш нәтиҗәләре өчен түләүләр. Бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә муниципаль берәмлекләр бюджетларына күрсәтелгән түләүләр спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары спортчы-инструкторларына һәм спортчыларына түләүләр тигез кабул ителә;

Чсрj - ярышларда урыннар били торган спортчы-инструкторларның һәм уңышлы чыгышлары булган спортчыларның еллык саны һәм, спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмасында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы тарафыннан муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары мәгълүматлары нигезендә Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә соңгы ике тәмамланган финанс елында күрсәтелгән спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның факттагы саны турында Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы планлаштыра торган j-муниципаль физкультура спорт оешмасында ирешелгән нәтиҗәләр;

Сj - муниципаль физкультура спорт оешмасы хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча түләүләргә исәпләнгән чыгымнар;

п - Татарстан Республикасының i-муниципаль берәмлегендә спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары саны.

9. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Министрлыкка югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга спорт резервын әзерләүче ярышларда ирешкән уңышлары өчен бүләкләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар алуга әлеге Нигезләмәгә кушымта һәм ярышлар беркетмәсе күчермәсе нигезендә гариза (заявка) (алга таба - гариза)

бирә.

10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә финанслауның иң чик күләмнәрен тиешле календарь айга (Sjm) җиткерү өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Sim = Znj = 1 ((Ov \text{ X } \text{Ч}tpj) + (Bvrr \text{ X } \text{Ч}cj) + Cj),$$

биредә:

Ov - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән билгеләнгән физик культура һәм спорт өлкәсендә программаларны гамәлгә ашыручы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмасында алынган урын нигезендә югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерлар оклады. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә күрсәтелгән окладлар спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары тренерларының окладлары тигез кабул ителә, ул Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 23 декабрендәге 853 номерлы

"Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» карары белән билгеләнгән;

Чtpj - спорт резервын әзерләүче j-муниципаль физкультура спорт оешмасында югары квалификацияле спортчылар әзерләүче тренерларның хисап аена факттагы саны;

Bvrr - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында Спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында" 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы карары белән билгеләнгән спорт инструкторларына югары эш нәтиҗәләре өчен ярышларда һәм спортчыларга уңышлы чыгыш ясаулары һәм рәсми халыкара, бөтенроссия һәм республика ярышларында, спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура оешмасында ирешелгән уңышлары өчен түләү. Бюджетара трансфертлар күләмен исәпләгәндә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына күрсәтелгән түләүләр спорт резервын әзерләүче дәүләт физкультура спорт оешмалары спортчы-инструкторларына бертигез түләүләр белән кабул ителә;

ЧCj - ярышларда урыннар биләгән спортчы-инструкторларның һәм уңышлы чыгышлары булган спортчыларның саны, спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмасында хисап аена рәсми бөтенроссия һәм халыкара ярышларда ирешелгән нәтиҗәләр;

Cj - муниципаль физкультура спорт оешмасы хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча түләүләргә исәпләнгән чыгымнар;

п - Татарстан Республикасының і-муниципаль берәмлегендә спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмалары саны.

11. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Спорт

министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты арасында төзелә торган килешү нигезендә (алга таба - килешү) тиешле финанс елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча бирелә, анда түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше; бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме; башка бюджетара трансфертларны күчерү сроклары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре; Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануын тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылыкның башка бюджетара трансфертлар алучыга бирү тәртибе, формасы һәм сроклары һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү;

әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы.

12. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервы әзерләүче муниципаль физкультура оешмаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җыелма спорт командалары әгъзалары яки кандидатлар булып торучы спорт әзерлеге узучы затлар саны башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) максатчан күрсәткече булып тора.

14. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар тулы күләмдә бирелә торган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре, килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү зарурлыгыннан чыгып, җирле бюджет турындагы карар белән раслана (Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасы белән билгеләнә).

15. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге югары квалификацияле спортчылар әзерләүче тренерлар, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында алынган нәтиҗәләргә ия спортчы-инструкторлар һәм спортчылар реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына башка бюджетара трансфертлар бирүгә реестр һәм гариза бирә.

16. Министрлык агымдагы айның 15 числосыннан да соңга калмыйча ай саен югары квалификацияле спортчылар әзерләүче тренерларның, шулай ук ярышларда алынган нәтиҗәләре булган спорт резервын әзерләүче муниципаль

физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларның һәм спортчыларның җыелма реестрын алып бара, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына башка бюджетара трансфертлар бирүгә гариза бирә.

17. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы башка бюджетара трансфертлар бирү өчен, Министрлыктан заявка алганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка әлеге максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерүгә чыгым расписаниесен җибәрә.

18. Министрлык күрсәтелгән максатларга финанслауның иң чик күләмнәре җиткерелгән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Банкының исәп-хисап челтәре бүлекчәләрендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты акчаларын исәпкә алу өчен ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең исәп-хисап счетына башка бюджетара трансфертлар күчерә.

19. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының башкарма комитеты ай саен хисап аеннан соң килүче айның 15 көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Арча муниципаль берәмлегенең финанс белән тәэмин итү чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган чыгымнары турында һәм килешү нигезендә башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турында хисаплар тапшыра.

20. Министрлык ай саен хисап аеннан соң килүче айның 20 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларының чыгымнары турында финанс белән тәэмин итүнең чыганагы башка бюджетара трансфертлар булган хисапларны тапшыра һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән рәвештә башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәүне тапшыра.

21. Әгәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башка бюджетара трансфертлар бирелгән елның 31 декабренә әлеге Нигезләмәнең 13 пунктында каралган күрсәткечләргә ирешмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соң килүче елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар суммасы (V кире кайтару) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

V кире кайтару Vмбт * к х 0,1 ,

биредә:

Vмбт - хисап финанс елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

к - башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

22. Хисап финанс елында (VМбт) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акчалар күләмен исәпләгәндә, Татарстан Республикасы бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендәге башка бюджетара трансфертларның башка бюджетара трансфертлар бирелгән елдан соңгы елның 1 гыйнварына файдаланылмаган өлеше исәпкә алынмый.

Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты (к) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$К = 1 - \frac{T}{S},$$

биредә:

Т - фактта ел ахырына ирешелгән башка бюджетара трансфертны файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткече;

S - килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертларны файдалануның нәтиҗәлелеге пландагы күрсәткече.

23. Әлеге Нигезләмәнең 23 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, шул исәптән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүр итү чаралары кулланыла.

24. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар акчалары агымдагы финанс елның беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә түләнергә тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансферларга ихтыяҗ булу турында Министрлык карары нигезендә, күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артмаган күләмдәге акчалар, күрсәтелгән бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен агымдагы финанс елында муниципаль берәмлек бюджеты керемәнә кире кайтарылырга мөмкин.

25. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөреслеге һәм башка бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмау өчен законнар нигезендә җаваплы.

26. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшереп тору законнар нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга,
шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының
спорт резервын әзерли торган муниципаль физкультура- спорт
оешмаларында эшләүче спортчы - инструкторларга һәм спортчыларга
ярышларда ирешкән нәтиҗәләре өчен бүләкләр бирү турында
Нигезләмәгә кушымта
Форма

**Югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен тренерларга, шулай ук спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы муниципаль физкультура оешмаларында эшләүче спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләр өчен бүләкләүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар алуга гариза (заявка)**

| N | Физкультура - спорт оешмасы исеме | Тренерның Ф.И.А.И. | Спорт төре, спорт төрләре бөтенроссия реестры нигезендә дисциплина, спорт төренең тулы исеме | Спорт төрләре бөтенроссия реестры нигезендә спорт дисциплинасы номер-коды | Спорт төрләре буенча төбәкара һәм бөтенроссия спорт ярышлары турындагы нигезләмә нигезендә дисциплинаны тәкъдим итүче спортчылар саны, кеше | Шөгыльләнүченең Ф.И.А.И. | Алынган урын | Ярышларның дәрәҗәсе | База оклады | 1 шөгыльләнүче өчен % | Сумма, сум | Тренерлар саны, кеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | |